**Ләбиб Лерон**

**Борчак шыттырам**

БЕРЕНЧЕ БОРЧАК
Шалтмылтфильмнар

Рәссамы ***Фәрит Муллахмәт***

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат) 6
Л 47

**Леронов Л. Л.**

Борчак шыттырам: Беренче борчак: Шалтмылтфильмнар / Ләбиб Лерон.— Казан: Мәгариф, 2006.—39 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1570-1

ISBN 5-7761-1570-1
© «Мәгариф» нәшрияты, 2006
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

## СӘЕР ИЛ

Дөньяда бер сәер ил бар —
Беркөн булдым мин анда.
Күргәннәрне түкми-чәчми
Сөйләп бирим сиңа да...

Анда тавыклар, чебиләр
Һавада очып йөри.
Көрәк чаклы кашык белән
Әтәчләр карлар көри.

Гаҗәп инде, каз-үрдәкләр
Анда карда коена.
Агачлардан яфрак түгел,
Кәгазь акча коела.

Анда беркем тырай типми,
Эшсез йөрми аптырап:
Ак болытка кармак салып,
Мәче балык каптыра.

Агач мылтыкларын сөйрәп,
Этләр ауга йөриләр.
Куак асларына посып
Дер-дер килә бүреләр.

Төлкеләр дә дер калтырый —
Тавыкларны күрсәләр;
Агачларга үрмәлиләр —
Этләр «һау-һау» өрсәләр.

Куяннарның эше хутта —
Алар хуҗа урманга:
Мультиклар карап яталар
Төренеп ак юрганга!

Бу илдә дә, бездәге кук,
Таңнар сызылып ата.
Бу илдәге бала-чага
Карда кызынып ята.

Малай-шалайлар бу илдә
Кызлар чәчен тартмыйлар.
Гаҗәеп хәл: йокларга да
Алар соңлап ятмыйлар.

Кибетләрдә: «Моны ал!» — дип,

Беркем елап йөдәтми.
Киресенчә: «Алам!» — дисәң,
Әйтә барсы: «Кирәкми!»

«Иртәме соң, кичме соң?» — дип,
«Төнме соң бу, көнме?» — дип,
Йөрдем-йөрдем мин бу илдә
«Төшме соң бу, өнме?» — дип...

...Вакыт тапса, Кыш бабакай
Алып барыр сине дә
Мин булган шул сәер илгә —
Әкиятстан иленә.

**АЛДАР ХӘКИМ**

Илләр гизеп йөрмәсәм дә
Беләдер мине һәркем:
Фамилиям — Габсаматов,
Исемем — Миңлехәким.

Сезнең өй түбәсе — салам,
Безнеке калай инде.
Сүз эзләп кесәгә кермим —
Мин шундый малай инде!

Тумыштан ук бик гайрәтле,
Көчле малай мин үзем:
Сазга баткан тракторны
Чыгардым мин берүзем!

Мактану ул — яман гадәт,
Алдашуы — бигрәк тә...
Пропеллер ясадым мин
Беркөн ике көрәктән!

Тәвәккәллек-җитезлектә
Узалмый мине беркем:
Әсма түти кәҗәсенә
Атланып йөрдем беркөн!

Авылдагы барча кеше
Бездән үлеп көнләшә:
Бишектәге минем энем
Сигез телдә сөйләшә!

Мин үзем дә вундеркинд бит —
Тугыз телдә сөйләшәм...
Утыз телдә җырлый алам,

Әгәренки теләсәм!

Сарык телен дә беләм мин,
Тавык телен дә беләм.
Кирәк икән, чичичиләп,
Тычкан телендә көләм!

Әллә-әллә нәрсәләргә
Җитәрлек минем хәлем —
Беркөн күккә менеп төшеп,
Яңгыр яудырдым әле!

Тагын беркөн күккә менеп,
Йолдызлар чүпләп төштем.
Соңгы йолдызны өзгәндә,
Уч төбем яман пеште...

Мактану ул — яман гадәт,
Алдашуны әйтмим дә...
Күккә очу берни тормый
Габсаматов Хәкимгә!

Бер генә кимчелегем бар:
Сүзне кире боралмыйм.
Мактануын мактансам да,
Алдашмыйча торалмыйм.

## ШУНДЫЙ-ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР

Олыймән мәктәбендә
Шундый хәл булды беркөн...
(Мондый хәлнең булган чагын
Хәтерләмидер беркем!)

...Кәрим, Сәлим һәм Хәким
Уйнаганда туп тибеп,
Челпәрәмә килде тәрәз
Пыяласы туп тиеп!

Ни хикмәттер, малайларны
Ник берәрсе орышсын.
«Кем ватты?» да
«Кем ватты?» дип,
Никләр берсе сорашсын...

Киресенчә: «Ачуланмыйк,
Алыйк мактап та»,— диләр...

«Бик шәп футболчылар үсә
Безнең мәктәптә!» — диләр...

Бер агарды, бер кызарды
Малайларның йөзләре,
Хәтта директор абый да
Мактап алгач үзләрен...

...Дәрес бара. Укытучы
Мәзәк сөйләп көлдерә.
Кая ул өй эшен сорау,—
Көлә алсаң көл генә!

Дәрес ахыры җиткәндә,
«5»ле куя һәркемгә...
Мәзәк сөйләп, ике «5»ле
Алды хәтта Хәким дә!

...Кәгазь күгәрченнәр ясап
Очырганда һәрберсе,
Җырлап кына үтеп китә
Татар теле дәресе!

... Тәнәфестә кызыйларны
Куркытып вә өркетеп,
Маймыллана малай-шалай,
Мәктәпне дер селкетеп.

Кайсы куа, кайсы кача —
Куышалар, янәсе...
Авыздан куык чыгарып,
Сагыз чәйни һәммәсе!

Укытучылар да бергә
«Әбәк-чәбәкле» уйный,
Тик нигәдер Хәким генә
Аңлый алмый һич шуны!

...Гел-гел шулай икән, диеп
Уйлый күрмә тагы син:
Болар — төштә күргән хәлләр...
Ни булыр иртәгесен?

## АЙДАР ҺӘМ ЮЛБАСАРЛАР

Сез әле белмисездер дә,
Бик шәп беләм мин аны —

Олыймән дигән авылдан
Айдар дигән малайны.

Бик инсафлы, бик тәртипле,
Бик матур малай инде.
Чебеннән дә курыкмаса,
Бик батыр малай инде.

Беркөн шулай мәктәптән ул
Кайтып килгән чагында,
Кинәт юлын үзгәртте дә
Китте урман ягына.

Үзе атлый, үзе курка:
«Очрамасмы Шүрәле?»
...Каршысында пәйда булды
Юлбасарлар бермәлне!

Юлбасарлар кем диген?!—
Куян, Төлке һәм Бүре:
Кәкре таяклар белән
Коралланган һәрбере.

Куяннары башлык икән —
Фәрманыннан сизелә:
— Әй малай! Бар байлыгыңны
Чыгарып сал тиз генә!

Бүре, Төлке гайрәт чәчә:
— Күрсәт,— диләр,— букчаңны!
Арт сабагың укытканчы
Биреп кал син акчаңны!

Шундый чакта син төшенми,
Аңламый кара әле:
Чебен хәтле чебеннән дә
Курыккан Айдар хәлен!

...Бүре букчаны ачуга
Килеп чыкты «5»леләр...
Ике «5»ле һәм бер «4»ле
Һөҗүмгә үк күчтеләр.

Айдарның хәле яхшырды —
Карап кына тора ул.
Юлбасар Куян кычкыра:
«Үтерәләр! Каравыл!»

Билгеләрнең көч-гайрәтен
Юлбасарлар татыды:
— Күрмәдек,— диләр,—
моңарчы
Бу малай күк батырны!

Бу әкият-мәкиятне,
Бүген көндез-өйләдә,
Чебеннән дә курыкмаган
Айдар үзе сөйләде.

## ГӨЛНӘЗИРӘ —МАТУР КЫЗ

Күршебездә бер кыз яши —
Бик матур кызый инде.
Кистергәнгә кадәр чәче
Бигрәкләр озын иде.

Хәер, аңа кыска чәч тә
Килешеп тора үзе.
Гөлнәзирә гүзәлкәйнең
Гел балкып тора йөзе.

Гөлнәзирә телевизор
Карарга бик ярата.
Аның күк кино караучы
Юк безнең Бикнаратта.

Гөлнәзирә китаплар да
Укый — вакыт булганда.
Такыялар үреп кия,
Барса әгәр урманга.

— Үскәч артист буламын!— ди,
Көзгегә баккан саен.
Татлы хыялга бирелә,
Йокларга яткан саен.

Өйдә аны һәммәсе дә
Иркәли, назлап сөя:
— Безнең бердәнбер кызыбыз
Бигрәкләр чибәр! — дия...

— Аяклары туңмасын,— дип,
Оек бәйли әбисе.
— Кайнар ризык ашасын,— дип,
Аш пешерә әнисе.

Әтисе дә кибеттән гел
Аңа тәм-томнар ташый...
Тәм-томны бик ярата ул —
Һәммәсен үзе ашый.

Үзе ашый, үзе җырлый,
Күз төшерә көзгегә:
Сокланыплар карап тора
Көзгедәге йөзенә.

Тузан сөртә, идән юа,
Камыр куя әнисе.
Әтисе бәрәңге әрчи,
Суган турый әбисе.

Өйдә беркем эшсез тормый —
Бигрәк эшчән кешеләр.
Гөлнәзирә күлмәк сайлый —
Аның да үз эше бар.

Анда — күлмәк, монда —
 күлмәк:
Шыплап тулган бүлмәсе.
Бигрәкләр дә матур кыз шул...
Их, ялкау да булмаса...

## БЕЗНЕҢ АВЫЛ — ЗУР АВЫЛ

Безнең авыл — бик зур авыл:
Йортларының чуты юк...
Каравыл өенең генә
Тәрәзендә уты юк.

Безнең авыл — бик зур авыл:
Кешеләре меңләптер...
Белгәнемне сөйлим сиңа —
Иплэп кенә тыңлап тор.

Гаҗәп хәлләр, сәер хәлләр
Безнең авылда инде:
Яңгыр кебек ява бездә
Йолдызлар көпә-көндез!

Урамнарга чыгар хәл юк —
Көн дә кызык тамаша:
Чана тартасы урынга

Этеп йөри алаша!

Малайларны кызыктырып,
Кәҗә йөртә машина.
Ялгыш таптап китүе бар —
Чыга күрмә каршына.

Ботинканы чана итеп,
Бер тычкан сөйрәп килә...
Ике үрдәк аңа карап,
Эчләрен тотып көлә.

Кибеттән йомырка алып
Кайтып килә бер тавык...
Бозлавыкка юлыктымы —
Тәпие китте таеп!

Сыер да тавык шикелле
Кибеткә барган бугай...
Авызы колакка җиткән —
Сөт-каймак алган бугай.

Бер абзардан ишетелә
Үгезнең җыр сузганы:
— Олы юлдан атлар килә,
Безгә кала тузаны-ы-ы...

Таң калырлык шундый хәлләр
Безнең авылда инде...
Сездә булмаган тәм-томнар
Безнең табында инде!

Үз күзең белән күрерсең,
Ышанмасаң сүзләргә.
Мин авылда булмаганда
Килеп кит бер безгә дә!

Ап-ак басуда күрерсең
Мин шыттырган борчакны...
...Бу хәлгә ышана яздым
Мин үзем дә бер чакны...

## ШҮРӘЛЕ КИЛДЕ КАЗАНГА...

Хәйран калды барча халык —
Абзыйлар вә түтиләр:
— Күр әле, безнең Казанга

Шүрәле килгән!— диләр.

«Башкалага ара ерак»,—
Диеп бер дә тормаган:
Арчадан килгән Шүрәле —
Кырлай хәтле Кырлайдан!

Казан урамнарын гизде,
Трамвайга утырып.
Прәннек, туңдырма ашады,
Авызларын тутырып.

Кабан күлдә, Казансуда
Су коенып алды ул.
Бармак-кармаклары белән
Балык тота язды ул.

Шулай йөри-йөри торгач,
Циркка да керде ул.
Тамашаның да кәттәсен
Менә шунда күрде ул.

Аю бии, этләр җырлый,
Казлар тарантас йөртә...
Клоуннар сүзсез-нисез
Бар халыкны көлдертә.

Бермәлне тамашачылар
Күрделәр Шүрәлене:
— Әй Шүрәле, безләрнең дә
Күңелен күр әле бер!

Шүрәлегә җитә калды —
Аренага элдерде.
Залдагыларның барчасын
Кытыкламый көлдерде.

Цирктан соң зоопаркка,
Театрга барды ул.
«Шүрәле» балетын карап,
Бик тә хәйран калды ул.

Төнге Казанны сокланып,
Күзәтеп карап йөрде.
Тукай, Җәлил һәйкәлләрен
Һәм Кремльне күрде.

Мин дә йөрдем Казан буйлап,

Шүрәле белән бергә.
Тәмле-татлы чәкчәк белән
Чәй эчеп чыкты бездә.

Арчасына, Кырлаена
Кайтып китәр алдыннан,
Сурәткә дә төштек әле
Кабан күле янында.

## СӘЛИМ МАЛАЕ ХӘЛИМ

Минем ис-акылым китеп,
Шаккатып торган мәлем:
Ни генә уйлап чыгармый
Сәлим малае Хәлим!

Бүген дә бик шәп-шәп уйлар
Килде аның башына:
«Ә» дигәнче ясады ул
Тәгәрмәчсез машина!

Хәзерге зур самолётлар
Булып чыкты яраксыз...
Ул ясаган самолётлар
Оча күктә... канатсыз!

Кайбер малай-шалайларның
Очасы бик килсә дип,
Ясады өч тәгәрмәчле,
Ак канатлы вилсәпид!

Торган саен аның башы
Шәбрәк эшли башлады:
Сыер, сарык көтәр өчен,
Робот ясап ташлады!

Ул ясаган көймә-кораб,
Шаклар катарлык — күрсәң:
Моторсыз йөзә дә китә...
Ике тапкыр төчкерсәң!

Ул ясаган тимер атлар
Тыр-тыр-тырылдап чаба...
Сапсыз-җепсез кармакларга
Балыклар җырлап каба!

Ул ясаган өй-йортларның

Һәммәсе дә аяклы;
Кайберләре генә никтер
Аяклы да таяклы!

Сәлим малае Хәлимнең
Һәр эшкә кулы ята:
Ул ясаган чаңгыларда
Запаска өчәр ката!

Ул ясаган чаналарны
Күрсәң исең китәрлек:
Тауга каршы «әһ» дигәнче,
Шундук менеп җитәрлек!

Кулга оста, әйткән дә юк,
Талантлы безнең Хәлим;
Рәсемнәрен син дә күрсәң
Шаклар катарсың әле!

Башы шәп эшли малайның —
Башлы малай шул Хәлим;
Әллә ниләр майтарыр ул
Укый дә белсә әле.

## ГАЛИ БАТЫР

Һәр авылның чибәр кызы,
Матур малае була.
Көч-гайрәте ташып торган
Батыр малае була.

Яздә дә бар шундый батыр —
Исеме Гали аның;
Иң яраткан энесе ул
Апасы Галиянең!

Гали батыр һич курыкмый
Беркемнән, бернидән дә...
Агач мылтык янда булса
Курыкмый бүредән дә!

Гали батыр күренүгә,
Барчасы да куркалар:
Усал этләр, ата казлар,
Голдыр-голдыр күркәләр...

Гали батыр иң-иң усал

Үгезне дә җиңәлә.
Һич тиктормас яшь тайны да
Ул берүзе җигәлә.

Гали батыр төнлә тышка
Курыкмыйча чыгала.
Мәктәптәге һәр малайны
Бармак төртеп егала.

Гали батыр ега ала
Әзмәвердәй Нилне дә.
Бер сугуда аударала
Фил кадәрле филне дә!

Крокодилны очратсамы?!—
Җиңә ала аны да.
Карап торса, ул җиңгәнне
Раслар иде Бану да.

Арысланнар, юлбарыслар
Гали өчен чүп кенә:
Шундук тәгәрәп китәләр,
Кулы тисә чүт кенә!

Гали батырны күрсәләр,
Качсалар да качмыйлар:
Юлбасарлар һәм пиратлар
Дер калтырый башлыйлар.

Гали батырны күрүгә,
Син башыңны иярсең.
Сокланыплар карап аңа:
«Терминатор!»— диярсең...

...Бу дөньяның иң батыры
Булыр безнең чорларда,
Курыкмаса әгәр Гали
Өйдән тышка чыгарга.

## САБАНТУЙ ГАЛӘМӘТЛӘРЕ

Кемнәргәдер — Вәлиәхмәт,
Кемнәргәдер — Вәли мин.
Сабантуйда күргәннәрне
Сөйләп бирим әле мин...

...Атлар җигеп, чана тагып,

Сабантуйга киттем мин.
Сабантуй бетә язганда,
Бик тиз килеп җиттем мин.

Сездә көрәш көрәшмени,
Бездә көрәш — зерә шәп:
Батырлар елап яталар...
Ике әби көрәшә!

Кайда — көрәш, кайда —
ярыш —
Шунда инде карчыклар:
Башка киеп йөгерәләр
Мендәр тышын, капчыклар...

Сездә — атлар чабышыдыр,
Бездә — кәҗә ярышы;
Бер сарык, катнашмас өчен,
Ярты сәгать карышты!

Капчык белән сугышулар —
Безнең якта ят нәрсә...
Бездә капчыклар үзләре
Дөмбәсләшә... Вәйт нәрсә!

Колга башына менүләр
Сездәгечә үктер, дим:
Безнең Гали, төшәлмичә,
Ике сәгать үкерде!

Тәгәрәп көләр идегез —
Гыйлемдарны күрсәгез:
Чүлмәк ватам дигән чакта
Шартлап сынды күсәге!

Әсма түти терек-терек
Йөгергәндә әлсерәп,
Кашыктагы күкәеннән
Чеби чыкты чәчерәп!

Башта һәркем көлеп карап
Торган иде Хатыйпка...
Барчабыз да куркып киттек,
Башын алгач катыктан!

Мин дә инде йөрмәдем гел
Хәйран-вәйран болганып...
Аумасын дип тотып тордым

Авыш шома колганы!

Сезнең якларда ничектер,
Бездә менә быел да
Шундый-шундый галәмәтләр
Булды Сабан туенда!

## АУЧЫ БАРЫЙ

Киләчәкне үткәндә,
Үткәннәргә җиткәндә,
Кышын авыр арбага
Яшь таракан җиккәндә,
Сукыр тычкан, әлсерәп,
Бозда иген иккәндә
Яши иде бер малай —
Буе булыр колгадай!

Яши иде, бар иде,
Исеме Барый иде.

Байтак агач тураклап,
Төзлеген карый-карый,
Мылтык ясады, шәпләп,
Менә шул Колга Барый.
Бер мылтыкка исәпсез
Агачлар кереп китте...
Тәки Барый мылтыгын
Алты көпшәле итте!

Көпшәләр «шәп» — һәрбере
Кәкере дә бөкере...
Бер көпшә уңга карый,
Ә берсе сулга карый,
Икесе өскә карый,
Калганы аска карый.
Җеп булгангамы бавы —
Мылтыгы шактый авыр:
Көчкә күтәрде Барый —
Гайрәт бар әле ярый!

Бүрттерелгән борчаклар
Кесәгә салды Барый.
Кирәге чыгар диеп,
Тары да алды Барый.
Ау өчен ниләр кирәк —
Барын да алды Барый.

Көннәр суык торганга
Төренде ул юрганга.
Сырган чалбар кигәндә
Сыгылдылар идәннәр.
Башына элде бүрек —
Чыпчыклар көлде күреп.
Аякка киде ката —
Атлаган саен бата.
Сыңар бияләй киде,
Ансы да тишек иде.
Сынса да сынар икән —
Чаңгы да сыңар икән.

Төш вакыты узганда
Китте Барый урманга:
Сыңар чаңгысын сөйрәп,
Авыз эченнән көйләп.

Урман юлы көрт тә көрт,
Барый бара керт тә керт.
Шулай сыңар чаңгыда
Атлап шуган чагында,
Күр, кашына-кашына,
Аю чыкты каршына!
Кыш буе йоклар чакта,
Йокысын бүсәр чакта,
Урманда нишләп йөри —
Ни калган Аюзатка?

Барый мылтык төзәде,
Дер-дер килде тезләре.
Ап-ак булды йөзләре,
Шакмак булды күзләре.
Аю шәрран акырып
Төртеп екты Барыйны.
Аучы хәтле аучыны
Шулай егу ярыймы?

Аю китте кашынып,
Барыйга карый-карый...
Юрганына чорналып,
Торалмый ятты Барый.
Көч-хәл белән торгачтын,
Әз-мәз сулыш алгачтын,
Барый киде бүреген
Һәм кинәт ул дерт итте —
Күреп алды бүрене!

Мылтык күргәч, куркудан
Бүре качты уң якка.
Бүре күргәч, шүрләүдән
Барый качты сул якка...

Шактый кар ерды Барый,
Адашып йөрде Барый:
Сыңар гына булса да,
Чаңгы бар әле ярый.

Шулай йөргән чагында
Юлыкты ул төлкегә:
Барый тайды тиз генә,
Калганчы дип көлкегә.
Күргән иде боланны —
Барый хәтле Барыйның
Уттай кызды колагы!
Күргәч ялгыз пошины,
Тары атмакчы булды —
Кесә генә буш иде.
Аю еккан чагында
Төшеп калган тарысы,
Борчагы да — барысы.

Шулай итеп, мылтыгы
Тары да аталмады,
Борчак та аталмады...
Табыш белән аучыбыз
Өенә кайталмады.
... Янып-пешеп, әлсерәп,
Мылтык һәм чаңгы сөйрәп,
Сөйрәп калын юрганны,
Барый өйгә юл алды.
Арган-талган хәлендә,
Шулай кайткан мәлендә
Күреп алды куян ул —
Фил кадәрле куянны!
Безнең аучыбыз Барый
Шундый-шундый куанды!..

...Һәм йокыдан уянды.

## БОРЧАК ШЫТТЫРАМ

Бервакыт бүген кичке иртәдә барлы-юклы киемнәремне чишенеп киендем дә искитмәслек гаҗәп төшләр күрә-күрә киттем Борчакшыттырам иленә. Барам

шулай, барам... Өй эче галәмәт суык — маңгайдан шабыр тир ага, керфек очларыннан бозлар тама. Туңмас өчен күлмәк сәдәпләрен ычкындырып җибәрдем дә юрганны ныграк бөркәндем. Барам шулай, барам... Үзем бик матур итеп гырлыйм, бик яман итеп җырлыйм. Аяк астында — кар, авызда тешләр шыгырдый. Үзем барам, үзем юрганга ныграк төренәм. Борын белән куык кабартып очырам да тирә-юньне күзем белән кәртечкәгә төшерәм. Җил сызгыра, кояш кыздыра, ә мин тузан туздырам. Биткә кар сылана, бөтен өс-баш чыланганнан-чылана. Бияләйнең суын сыгып кигән идем — аякларым туңа башлады. Ярый әле ике кат тишек оекбаш кигән идем. Киез каталар да кигән булсам, катып үләргә дә күп калмый иде. Тамак тук булуга карамастан, ашыйсы килә башлады. Юрганның төпсез кесәләрен кармалый торгач, чикләвек хәтле борчак таптым. Тотындым шуннан соң борчак шыттырырга. Әй шыттырам борчак, әй шыттырам... Шыттырам да шытымын сиңа тоттырам, шыттырам да шытымын сиңа тоттырам...

Уянып китсәм, син бар — мин юк. Син әйткәч кенә белдем, мин һаман Борчакшыттырам илендә борчак шыттырам икән. Шыттырам да шытымын сиңа тоттырам икән...

**ЭЧТӘЛЕК**


| | |
|---|---|
| Сәер ил ........................................ | **3** |
| Алдар Хәким .............................. | **6** |
| Шундый-шундый хәлләр ............ | **9** |
| Айдар һәм юлбасарлар ............ | **12** |
| Гөлнәзирә — матур кыз ............ | **15** |
| Безнең авыл — зур авыл .......... | **18** |
| Шүрәле килде Казанга... ............ | **21** |
| Сәлим малае Хәлим ................. | **24** |
| Гали батыр ................................. | **27** |
| Сабантуй галәмәтләре ............. | **30** |
| Аучы Барый ............................... | **33** |
| Борчак шыттырам ..................... | **37** |

Литературно-художественное издание

Для младшего школьного возраста

**Лерон** Лябиб
***(Леронов*** *Лемон Леронович)*

**ЛАПША НА УШИ**
**КНИГА ПЕРВАЯ**
*Комиксы*

Әдәби-нәфис басма

**Лерон** Лябиб
***(Леронов*** *Лемон Леронович)*

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

**БОРЧАК ШЫТТЫРАМ**
**БЕРЕНЧЕ БОРЧАК**
*Шалтмылтфильмнар*

Редакторы *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректоры *А. М. Закирова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л. Р. Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.11.2006. Форматы 70x84$^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 2,73. Нәшер-хисап табагы 2,48. Тиражы 2000 д. Заказ З-1014.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif @ mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.